ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының $141^{1}$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» 123-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының $141^{1}$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» 123-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 29 октябре
№ 439-VII ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясына үзгәрешләр кертү турында**

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), 2025, № 18 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә «һәр опекага алынган бала өчен 3000 сум» сүзләрен «тәрбиягә алынган һәр бала өчен ай саен 8641 сум» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 – 5 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Педагогик һәм (яисә) медицина белеме булган опекуннарга яисә попечительләргә, опекада яисә попечительлектә торучы балалар санына карамастан, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән түләүгә 13 546 сум күләмендә өстәмә түләү билгеләнә.

4. Балага яки балаларга берничә опекун яки попечитель билгеләнгән очракта, түләү, шул исәптән аңа өстәмә түләү, опекуннарның яисә попечительләрнең берсенә билгеләнә һәм түләнә. Түләү, шул исәптән аңа өстәмә түләү, берничә опекун яисә попечитель арасында алар билгеләгән пропорциядә бүленергә мөмкин. Түләүне, шул исәптән аңа өстәмә түләүне опекуннар яисә попечительләр белән килештереп бүлү опеканы яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турындагы шартнамәдә күрсәтелә.

5. Опекуннарга яисә попечительләргә түләү, шул исәптән аңа өстәмә түләү чыгымнары да Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проекты (алга таба – проект) үз йөкләмәләрен түләүле нигездә үтәүче опекуннарның һәм попечительләрнең социаль якланганлык дәрәҗәсен һәм матди кызыксынуын арттыру, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның яшәүләре һәм тәрбияләнүләре өчен уңайлы шартлар тудыру, опека һәм попечительлек институтының абруен күтәрү максатларында эшләнде.

Үз йөкләмәләрен түләүле нигездә үтәүче опекуннарга яки попечительләргә тиешле түләүнең база күләме 2013 елдан яңадан каралмады һәм индексацияләнмәде һәм хәзерге вакытта заманча икътисадый шартларга туры килми, гражданнарны опекуннар һәм попечительләр вазыйфаларын башкаруга җәлеп итүгә булышлык итми. Шул ук вакытта Татарстан Республикасының кайбер муниципаль берәмлекләрендә (мәсәлән, Казан шәһәрендә) муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчалары исәбеннән өстәмә кызыксындыру акчалары түләнә.

Түләүнең түбән булу проблематикасының актуальлеге шулай ук Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил мөрәҗәгатьләрендә дә билгеләп үтелә.

Закон проектында Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясындагы 1 өлешен айлык түләү күләмен 3 000 сумнан 8 641 сумга кадәр арттыру нисбәтендә үзгәртү каралган.

2025 елның июленә тәрбиягә алган гаиләләрдә опекада яки попечительлектә булган балаларның гомуми саны 1788 бала тәшкил итә.

2026 елга тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларның гомуми саны 1600 кеше дип фаразлана, шуларның 230ы - өч яшькә җитмәгән балалар, йә инвалид балалар, йә психик яки физик үсешләрендә тайпылышлар булган балалар, йә девиант холыклы балалар.

Түләү күләмен үзгәртү өч яшькә җитмәгән балалар, йә инвалид балалар, йә психик яки физик үсешләрендә тайпылышлар булган балалар, йә девиант холыклы балаларны тәрбиягә алган гаиләләргә Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясындагы 2 өлешендә каралган түләүне арттыруга китерәчәк. Хәзерге вакытта 1788 баладан 271 бала шундый категориягә керә, 2026 елда – 230 бала.

Бер үк вакытта әлеге закон проекты белән Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясындагы 3 өлешендә каралган түләүгә өстәмә күләмен элек минималь хезмәт хакына исәпләнгән акчалата суммага үзгәртү күздә тотыла.

**«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының $141^1$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының $141^1$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының 2026 елдан башлап 189 031,3 мең сум күләмендә артуына китерәчәк.